2026 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ерсубайкино авылы җирлеге Яна Елань авылында гражданнарның үзара салымын кертү турында

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

13 ноябрь 2025 ел № 2

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әлмәт муниципаль районының Ерсубайкино авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ерсубайкино авыл җирлегенең Яна Елань авылында гражданнар җыены КАРАР кабул итте:

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ерсубайкино авыл җирлегенең Яңа Елань авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 4500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә: су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, (металл калынлыгына экспертиза, буяу), скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау».

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Яңа Елань авылы, Үзек урамы, 35 нче йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Ерсубайкино авыл җирлеге башлыгы А.В. Быков